**ГЛАВА**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31 .07.2023 Балык Бистәсе штп. № 172 пг

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендәге оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгының 2019 елның 11 мартындагы 54пг номерлы карары белән расланган Иҗтимагый совет турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасының «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендәге оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгының 2019 елның 11 мартындагы 54пг номерлы карары белән расланган Иҗтимагый совет турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Башлык Р.Р. Ислямов